**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Куакбаш авыл җирлеге**
**Чүте авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Чүте авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Куакбашавыл җирлеге Куакбаш авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Чүте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән: көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Чүте авылында (Гагарин ур., Тынычлык ур.) юлларны кардан чистарту

2.Чүте авылында җирләү урыннары территориясен төзекләндерү (агач кисү һәм чыгару):

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Куакбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Әхмәтҗанова